**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

2024 елның 6 июнендәге 2324 номерлы карары

# Казан шәһәренең Мәскәү районындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 75 кв.м;

- үзләренә карата хокуклар чикле булган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары 16:50:200103:187, 16:50:200103:13;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Мәскәү районы;

- билгеләү максаты: җирле әһәмияттәге ТП-1739 трансформатор подстанциясе электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру;

- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында»гы карары (2018 елның 21 декабрендәге редакциядә), Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, җирле әһәмияттәге ТП-1739 трансформатор подстанциясенә милек хокукы (2001 елның 26 декабрендәге 16-50.3-23.2001-1288.3) теркәлгән.

2. Әлеге карарга 1 номерлы һәм 2 номерлы кушымталарда күрсәтелгән җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Шәһәрне үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1 номерлы, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

4. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга

һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта<br>Казан шәһәре Башкарма комитетының<br>2024 елның 6 июнендәге 2324 номерлы<br>карары белән расланды

**16:50:200103:13, 16:50:200103:187 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб 1:500
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа барлыкка килгән характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:200103 | кадастр кварталы |
| 16:50:200103:13, 16:50:200103:187 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |